# Халык жыены карары

№ 1 20.11.2019 ел

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге составына керүче Түбән Стәрле авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «2020 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең Түбән Стәрле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300,00 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, укучыларның көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2 төркем инвалидлар өчен 150 сум күләмендә киметергә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү очен алынган акчаларны юнәлтү турында:

- Түбән Стәрле авылында Кызыл тан урамынын юлларына щебенка җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Түбән Стәрле авылында юлларны кардан чистарту;

- Түбән Стәрле авылында территорияләрне чүп үләннәреннән һәм чүп-чардан чистарту хезмәтләре;

- бүләк, сувенир продукциясе сатып алу, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Инвалидлар көне», «Яңа ел " бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү»;

РИЗА» «КАРШЫ».

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 53кеше, халык җыенында катнашучылар саны 41 кеше кергән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 41 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы составына керүче Югары Стәрле авыл җирлегендә узган халык җыенын халык җыенын утте дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре-дөрес.
2. "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Түбән Стәрле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300,00 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының һәм катнашучыларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2 төркем инвалидлар өчен 150 сум күләмендә билгеләргә һәм алган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнэлдерергэ:

- - Түбән Стәрле авылында  Кызыл тан урамынын юлларына щебенка җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Югары Стәрле  авылында юлларны кардан чистарту;

- Түбән Стәрле авылында территорияләрне чүп үләннәреннән һәм чүп-чардан чистарту хезмәтләре;

- бүләк, сувенир продукциясе сатып алу, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Инвалидлар көне», «Яңа ел " бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү» турындагы карары кабул ителде.

3.Әлеге халык җыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.  һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Югары Стәрле авылы, Совет ур., 32г йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Югары Стәрле авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Стәрле авыл җирлеге башлыгы: Сабиржанова Л.С.